| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2024 с. Лебяжье № 69

**Советның 21.11.2014 ел, №83 Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында, шулай ук Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр,чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыруы турында Карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Татарсан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 83 номерлы карарына 3 нче кушымтаның 6 нчы бүлегенең 6.2 пунктындагы 13 нче искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"<13> Әгәр дә мондый акчаларның гомуми суммасы кешенең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында һәм аннан алдагы ике елдагы гомуми кеременнән артып китсә, хисап чоры өчен счетларга кергән акчалар суммасы күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен суммалар Россия Банкының хисап датасына курсы буенча рубльдә күрсәтелә.".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлекнең рәсми сайтында ,«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Лебяжье авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Д.Ә.Гыйләҗов**